Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының
Мәмәт авыл Советы

КАРАРЫ

20 январь 2022 ел №33

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Мәмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру буенча Әлмәт районы Советы тәкъдимен кабул итү турында» 2021 елның 14 октябрендәге 23 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, «Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында Әлмәт муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән килешүләр төзү тәртибе хакында» Әлмәт муниципаль районының 2015 елның 6 маендагы 468 номерлы карары нигезендә

Мәмәт авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Мәмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру буенча Әлмәт районы Советы тәкъдимен кабул итү турында» 2021 елның 14 октябрендәге 23 номерлы карарына (алга таба- карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 карарның 1 пунктында «үзгәрешләр кертү өлешендә» сүзләреннән соң «(әзерләү һәм эшләү)» сүзләрен өстәргә;

2. Әлеге карарны Мәмәт авылы, Совет урамы, 1 йорт, Чупай авылы Совет урамы, 43А йорты, Сәмәрканд бистәсе, Үзәк урамы, 1 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә,

«Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мәмәт авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Мәмәт авыл җирлеге башлыгы И.М.Зөбәерова